Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында"**
**Татарстан Республикасы Законының 21 һәм 22 статьяларына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында" 2004 елның 24 мартындагы 25-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (IV өлеш); 2005 ел, № 12 (I өлеш); 2007, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 статьяның 29 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"29) "Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре";";

2) 22 статьяның 28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"28) "Татарстан Республикасының атказанган мәгълүматлаштыру һәм элемтә хезмәткәре" – мәгълүматлаштыру һәм элемтә тармагы предприятиеләренең һәм оешмаларының мәгълүматлаштыру һәм элемтә өлкәсендә кимендә 10 ел эшләүче югары квалификацияле хезмәткәрләренә элемтә чараларын үстерүдәге һәм камилләштерүдәге, шулай ук элемтә чараларының югары сыйфатлы, өзлексез эшләвен тәэмин итүдәге, инфокоммуникация инфраструктурасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттырудагы, халыкка, республика предприятиеләренә, учреждениеләренә һәм оешмаларына элемтәнең һәм инфокоммуникациянең

барлык төр хезмәтләрен күрсәтүне яхшыртудагы, принципиаль яңа югары нәтиҗәле техника һәм технологияләр эшләп чыгарудагы һәм аларны гамәлгә кертүдәге казанышлары өчен;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 30 июне
№ 43-ТРЗ